КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 28 февраль г.Казань № 139

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга авыл җирендә яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк затларны Татарстан Республикасы медицина оешмаларына алып баруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар исемлеген раслау турында» 2019 ел, 19 гыйнвар, 25 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасында «Демография» илкүләм проектының «Өлкән буын» өлкән буын гражданнарына системалы ярдәм күрсәтү һәм тормыш сыйфатын яхшырту программасын эшләү һәм тормышка ашыру» федераль проектын гамәлгә ашыру максатларында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019 елга авыл җирендә яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк затларны Татарстан Республикасы медицина оешмаларына алып баруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар исемлеген раслау турында» 2019 ел, 19 гыйнвар, 25 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә һәм 1 пунктта «2019 елга» сүзләрен «2019 – 2024 елларга» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган 2019 елга авыл җирендә яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк затларны Татарстан Республикасы медицина оешмаларына алып баруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар исемлеген яңа редакциядә бәян итәргә (houkарарга теркәлә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
вазыйфаларын башкаручы Р.К.Нигъмәтуллин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 - 2024 еллар, 19 гыйнвар, 25 нче
карарына кушымта
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 - 2024 еллар, 28 февраль, 139 нчы карары редакциясендә)

2019 – 2024 елларга авыл җирендә яшәүче
65 яшьтән өлкәнрәк затларны Татарстан Республикасы медицина оешмаларына
алып баруны тәэмин итүгә юнәлдерелгән чаралар
исемлеге

| Т/с | Чара исеме | Чараны тормышка ашыру вакыты | Җаваплы үтәүчеләр |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының авыл җирлегендә яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк затларны Татарстан Республикасы медицина оешмаларына илтеп җиткерү мәсьәләләре буенча ведомствоара хезмәттәшлек регламентын эшләү һәм раслау | 2019 - 2024 елларның I кварталы | ТР ХХЭбТИһСЯМ*, ТР ССМ |
| 2. | Авыл җирендә яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк затларны Татарстан Республикасы медицина оешмаларына китерүне оештыру өчен Россия производствосы автотранспортын сатып алуга федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар алу максатларында Россия Фе- | 2019 - 2024 елларның I кварталы | ТР ХХЭбТИһСЯМ |

* Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге – 4 биттә.

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | дерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгына гариза бирү | | |
| 3. | Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләре тарафыннан автотранспорт сатып алу өчен акча бүлү | 2019 - 2024 елларның 5 мартына кадәр | ТР ХХЭбТИһСЯМ |
| 4. | Авыл җирендә яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк затларны Татарстан Республикасы медицина оешмаларына китерүне оештыру өчен Россия производствосы автотранспортын сатып алу, шул исәптән аерым социаль әһәмиятле йогышлы булмаган авыруларны ачыклау өчен скрининглар үткәрү өчен | 2019 - 2024 елларның 1 июленә кадәр | ТРХСХККҮ, ТР ХХЭбТИһСЯМ, ТР Сатып алулар буенча дәүләт комитеты |
| 5. | Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүнең комплекслы үзәкләре буенча автотранспорт бүлеп бирү | 2019 - 2024 елларның 1 августына кадәр | ТР ХХЭбТИһСЯМ |
| 6. | Автотранспорт сатып алуга бәйле рәвештә 43 берәмлек күләмендә мобиль бригадалар төзү | 2019 - 2024 елларның II – III кварталлары | ТР ХХЭбТИһСЯМ, МЗ РТ |
| 7. | Авыл җирлегендә яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк затларны Татарстан Республикасы медицина оешмаларына китерүне оештыру өчен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының муниципаль районнардагы (бүлекләрендә), Татарстан Республикасы халыкка социаль хезмәт күрсәтүнең комплекслы үзәкләрендә һәм медицина оешмаларында җаваплыларны билгеләү | 2019 - 2024 елларның 1 августына кадәр | ТР ХХЭбТИһСЯМ, ТР ССМ, ТСЯБ, ТРХСХККҮ, УЗ, ҮРХ |
| 8. | Авыл җирлегендә яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк затларны Татарстан Республикасы медицина оешмаларына китерүне оештыру өчен Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының муниципаль районнардагы (бүлекләрендә), Татарстан Республикасы халыкка социаль хезмәт күрсәтүнең ком- | 2019 – 2024 еллар | ТР ХХЭбТИһСЯМ, ТР ССМ, ТСЯБ, ТРХСХККҮ, УЗ, ҮРХ |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | плекслы үзәкләрендә һәм медицина оешмаларында җаваплыларның контакт мәгълүматлары турында мәгълүмат алмашу | | |
| 9. | Татарстан Республикасы медицина оешмаларына Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүнең комплекслы үзәкләре автотранспорты белән китерелергә тиешле авыл җирендә яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк затларның персонификацияләнгән исемлеген эшләү | 2019 - 2024 елларның 1 августына кадәр | ТР ССМ, ТР ХХЭбТИhСЯМ |
| 10. | Авыл җирлегендә яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк затларны Татарстан Республикасы медицина оешмаларына Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтү комплекслы үзәкләре автотранспорт белән илтеп җиткерү план-графигын эшләү | 2019 - 2024 елларның 1 августына кадәр | ТР ХХЭбТИhСЯМ, ТР ССМ |
| 11. | Авыл җирлегендә яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк затларны Татарстан Республикасы медицина оешмаларына китерүне оештыру турында, шул исәптән аерым социаль әһәмиятле йогышлы булмаган авыруларны ачыклау өчен өстәмә скрининглар уздыру өчен, халыкка хәбәр итү | 2019 - 2024 елларның III кварталы – 2024 елның 1 декабре | ТР ХХЭбТИhСЯМ, ТР ССМ, ТСЯБ, ТРХСХККҮ, ССИ, ҮРХ |
| 12. | Авыл җирендә яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк затларны Татарстан Республикасы медицина оешмаларына илтеп җиткерү тәртипләрен (кагыйдәләрен) эшләү һәм раслау | 2019 - 2024 елларның II – III кварталлары | ТР ХХЭбТИhСЯМ, ТР ССМ |
| 13. | Яңа булдырылган мобиль бригадаларның эшчәнлеген оештыру, аларны карап тоту һәм финанслау | 2019 - 2024 елларның IV кварталы – 2024 елның 31 декабре | ТР ХХЭбТИhСЯМ |
| 14. | Татарстан Республикасы медицина оешмаларына китерелергә тиешле авыл җирендә яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк затларны ачыклау, шул исәптән аерым социаль әһәмиятле йогышлы булмаган | 2019 - 2024 елларның IV кварталы – 2024 елның 31 декабре | ТР ССМ, ТР ХХЭбТИhСЯМ |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | авыруларны ачыклау өчен өстәмә скрининглар уздыру өчен дә | | |
| 15. | Авыл җирлегендә яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк затларны Татарстан Республикасы медицина оешмаларына китерүне оештыру | 2019 – 2024 еллар | ТР ХХЭбТИhСЯМ, ТР ССМ, ТСЯБ, ТРХСХККҮ, ССИ, ҮРХ |
| 16. | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә авыл җирендә яшәүче 65 яшьтән өлкәнрәк затларга халыкның үлем-китем структурасына өлеш кертүче аерым социаль әһәмиятле йогышлы булмаган авыруларны ачыклауга өстәмә скринринглар уздыру | 2020 елның 1 гыйнвары – 2024 елның 1 декабре | ТР ССМ |

Файдаланылган кыскартылмалар исемлеге:

ТРХСХККҮ – Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтүче комплекслы үзәкләр;

ТР ССМ – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы;

ТР ХХЭбТИhСЯМ – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы;

ТР – Татарстан Республикасы;

ТСЯБ – Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының муниципаль районнардагы социаль яклау идарәләре (бүлекләре);

ССИ – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының Сәламәтлек саклау идарәсе;

ҮРХ – үзәк район хастаханәләре.